**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе Таҗи Гыйззәт исемендәге 3нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

# Тема: Идрис Туктар ”Дүрт кыз”хикәясе

**4 а сыйныфы әдәби уку дәресе (рус.төркеме)**

**Сингапур укыту методын кулланып уздырылган ачык дәрес эшкәртмәсе**

**Укытучы: Вәлиева Г.З.**

**21 февраль 2014**

**Дәрес төре :** Сингапур проекты буенча коммуникатив технологиягә нигезләнеп укучыларның белемнәрен ныгыту.

**Дәрес тибы:** укып аңлау күнекмәләрен чишү,белемнәрне актуальләштерү,коммуникатив һәм иҗади якын килеп эшләү

**Максат :** укучыларның татар телендә аралашу осталыкларын үстерү,хикәянең идеясен һәм геройларның гамәлләрен аңларга,үз фикереңне белдерергә өйрәтү,укучыларда әхлакый-эстетик сыйфатлар тәрбияләү,парлап һәм командалап сингапур методларына нигезләнеп күршең белән хезмәттәшлек итә белүне һәм аралашу культурасын кам илләштерү.

**Дәрес барышы**

**1 этап.** Оештыру моменты

а)дежур укучының отчетын тыңлау

б) фонетик зарядка уздыру : - тәр-тәр – Бу дәфтәр

- тап-тап- Бу китап

-ләм-ләм- Бу каләм

**2 этап.** Актуальләштерү

(өй эшен,сүзлек сүзләрен Клок Баддис структурасы буенча тикшерү)

**3 этап.** Таймд-Пэа-Шэа структурасы буенча эшләү .Хикәядәге кызларга характеристика бирү.

**4 этап.** Раунд-Тэйбл структурасы буенча эшләү.Командаларга бүленеп кызларга киңәшләр бирү,һәр командадан бер укучыга шул киңәшләрне укыту

**5 этап.** Контроль.Максат : - укучыларның игьтибарлыгын тикшерү. Мәкальләр укыту кайсы мәкаль хикәя эчтәлеге буенча туры килә ?

1.Кем эшләми, шул ашамый

2. Әдәпле булу-матур гадәт

3. Яхшы кешенең эшедә яхшы (җаваплар тыңлана)

**6 этап .** Педметара бәйләнеш. Русча,инглизчә әдәплелек турында нинди мәкальләрне табарга була? (укучыларның җаваплары тыңлана)

**7 этап.** Өй эше 2 төркемгә бүленеп бирелә. 1 нче төркем көчлерәк укучылар өчен- Хикәчне ничек үзгәртеп язарга мөмкин? Язып карарга.

2 нче төркем өчен – хикәягә сораулар куярга

Искәрмә.(Сингапур системасы буенча көчле укучылар өстәлдә укытучыдан ераграк утыралар,ә калган укучылар укытучыга якынрак утырырга тиеш).

**8 этап.** Билгеләр куела.

Искәрмә. (Сингапур системасы буенча һәр парның җавабын тыңлаганнан соң укучылар үзләре бәя бирергә мөмкин. Моның өчен алар баш бармак белән шул парга күрсәтеп Ш—-Ә----Ә----Ә----П

яки Б—И—Ш—Л—Е—Е дип кычкыралар.)